АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ
ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

**РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА** **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 12.03.2021 № ПР-8-2

г. Казань

**Туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган чаралар уздыру буенча муниципаль берәмлекләренең эше турында**

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары В. Г. Шәйхразыев мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе Президиумы (алга таба - Совет) **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары В.Г. Шәйхразыев мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

- Туган телләр һәм халык бердәмлеге елы кысаларындагы чараларны гамәлгә ашыру буенча эшне көчәйтергә;

- Татарстан Республикасы халыкларының тарихи-мәдәни мирасын саклауга һәм арттыруга, район, шәһәр һәм авылның гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә һәм әхлакый потенциалына нигезләнүгә аерым игътибар бирергә;

- Татарстан Республикасының «Созвездие – Йолдызлык» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы белән берлектә «Созвездие – Йолдызлык – 2021» эстрада сәнгатенең ачык республика телевизион яшьләр фестиваленең зона турларын уздырганда Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның милли сәнгатен чагылдыручы номерларны кертү мөмкинлеген карарга;

- «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Туган телләр һәм халык бердәмлеге елы кысаларында чаралар үткәрү турында хәбәр итәргә.

3. «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Туган телләр һәм халык бердәмлеге елы кысаларында үткәрелгән

чараларны республика һәм муниципаль массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Советның башкарма сәркатибе А.Г. Барышевка йөкләнә.

**Рәисе** **Ә.С.Гобәйдуллин**